| | | | - фикерне төгәл, ахырынача, эзлекле итеп җиткерә, дәлилли, дөрес яза,тылсымлы сүзләр телдән, язмача чакыру, тәбрикләү.<br>РУУГ:<br>- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау.<br>КУУГ:<br>- күршең белән хезмәттәшлек итү. | |
| **Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау** | - өйрәнелгән орфографик һәм пунктацион кагыйдәләрне кулланып, хатасыз яза белү | - бәйләнешле текст төзи белү өйрәнелгән орфограммалар кергән текстны хатасыз итеп яза белү;<br>- хаталарны таба һәм төзәтә белү;<br>- кагыйдәләргә нигезләнеп сүзләрнең дөрес язылышын аңлата белү. | ТБУУГ:<br>- үтелгән орфограммалар кергән текстны, тиешле тыныш билгеләрен куеп, диктант итеп яза;<br>- алган белемнәрне мөстәкыйль куллана текстның темасын һәм төп фикерен билгели, мәгънәле кисәкләргә, өлешләргә бүлә, кызыл юлны сайлый, текстка исем куя, төрләрен аера, планын төзи, сюжетлы картинага таянып хикәяләр | - үз мөмкинлекләреңне, белү-белмәү чикләрен чамалау;<br>- үз уңышларың уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү;<br>- укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уяту;<br>-тел аша әйләнә-тирә тормышка игътибар, дөрес мөнәсәбәт булдыру;<br>-укучыларның фикерләү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | төзи;<br><br>- алган белемнәрне практикада куллана; эзлеклелекне саклый; тест эшләрен тикшерә, бәяләү.<br><br>РУУГ:<br>- үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, тест һәм күнегүләр эшләү.<br>КУУГ:<br><br>- күршең белән хезмәттәшлек итү. | сәләтен үстерү;<br><br>-баланың үзенә һәм башкаларга бәя бирүенә, үз-үзен тәрбияләвенә ирешү. |

**Укыту предметының эчтәлеге**

| Бүлекләрнең исемнәре | Кыскача эчтәлек | «Мәктәп дәресе " тәрбия программасы модуле | Барлык сәгатьләр |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| **1-3 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау.** | Авазлар һәм хәрефләр. Аларның бүленеше. Сүзгә аваз-хәреф анализы. Татар телендә сингармонизм законы: рәт һәм ирен гармониясе. Иҗек калыплары.<br>Җәйге истәлекләр буенча инша язу. Кереш диктант.. | -укучылар һәм педагогик хезмәткәр арасында ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштыру<br>-укучыларның таләпләрен һәм гозерләрен уңай кабул итүгә, аларның игътибарын җәлеп итүгә ярдәм итүче укучылар белән очрашу; | **8сәг** |
| **Сүз. Телнең сүзлек байлыгы** | Сүзнең лексик мәгънәсе. Алынма сүзләр. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Тотрыклы сүзтезмәләр.Омонимнар. Синонимнар. Антонимнар. Лексикография турында мәгълъмат . Сүзлекләрне куллана белергә өйрәтү.<br>Изложение “Усак”. Тест. | -дәрестә фикер алышына торган мәгълүмат, аларның танып-белү эшчәнлеген активлаштыру; -укучыларның дәрестә гомуми кабул ителгән тәртип нормаларын, өлкәннәр һәм яшьтәшләре (укучылар) белән аралашу кагыйдәләрен, уку дисциплинасы принципларын үтәргә өндәү үзоешмалары; | **8сәг** |
| **Сүз төзелеше** | Тамырһәмкушымча.Сүз ясагыч, төрләндергеч кушымчалар. Кушма, парлы, тезмә сүзләр. Аларның ясалышы һәм дөрес язылышы. Сүз төзелешенә анализ ясау.<br>Картина буенча сочинение язу. Контроль диктант. | -дәресләрдә социаль әһәмияткә ия булган мәгълүмат белән эшләү – аның турында фикер алышуны башлап җибәрү, укучыларның аның уңаеннан үз фикерләрен әйтү, аңа карата үз карашларын булдыру-аларның эшен оештыру;<br>-дәрестә фикер алышына торган мәгълүмат, аларның танып-белү | **11 сәг** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | эшчәнлеген активлаштыру; | |
| **Сүз төркемнәре Исем** | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше.Калын һәм нечкә төрләнеш. Килеш кушымчаларының дөрес язылышы. Төрле килешләрдә исемнәрнең бәйлекләр белән кулланылуы.<br><br>Тест. Изложение “Хәйдәр коткарды”. | -дәрескә укучыларның белем алуга мотивациясен, сыйныфта уңай дустанә мөнәсәбәтләр урнаштырырга ярдәм итүче уен процедураларын кертү дәрес вакытында дустанә атмосфера булдырырга ярдәм итә;<br><br>-укучыларның тикшеренү эшчәнлегенә башлангыч бирү һәм ярдәм итү; | **8сәг** |
| **Фигыль** | Фигыль төркемчәләре. Аның зат-сан белән төрләнеше. Фигыльнең җөмләдә хәбәр булып килүе. Текстта синоним һәм антоним фигыльләрне куллану. Боерык һәм хикәя фигыль.<br><br>I яртыеллык өчен контроль диктант. Тест. | -дәрестә укучылар белән эшләүнең интерактив рәвешләрен куллану: укучыларның танып-белү мотивациясен стимуллаштыручы интеллектуаль уеннар; дидактик театр куллану, аларда дәрестә алган белемнәре ота белү. | **13 сәг** |
| **Сыйфат** | Сыйфат дәрәҗәләре. Дәрәҗә формаларының ясалышы, дөрес язылышы һәм кулланылышы. Сыйфатларның җөмләдәге роле. Антоним һәм синоним сыйфатлар.<br><br>Сочинение “Керпе”. Тест. | -укучыларның тикшеренү эшчәнлегенә башлангыч бирү һәм ярдәм итү,бу исә укучыларга теоретик проблеманы мөстәкыйль хәл итү, үз идеяләрен формалаштыру һәм рәсмиләштерү күнекмәләрен, башка тикшеренүчеләр эшендә рәсмиләштерелгән башка | **7 сәг** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | идеяләргә карата ихтирамлы мөнәсәбәт күнекмәләрен, аудитория алдында халык алдында чыгыш ясау, аргументлау һәм үз карашларын яклау күнекмәләрен алу мөмкинлеге бирәчәк. | |
| **Алмашлык** | Зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнеше һәм дөрес язылышы. Аларның бәйлекләр белән килүе һәм дөрес язылышы, күләм, чама белдерүче сүзләрне алмаштырып килүе. Алмашлыкларның җөмләдәге роле. Текстта кабатланып килгән исемнәр урынына - алмашлык,алмашлыклар урынына исем куллану. Сорау алмашлыклары.<br><br>Аңлатмалы диктант “Аны һәркем ярата”. Тест. | -дәресләрдә социаль әһәмияткә ия булган мәгълүмат белән эшләү – аның турында фикер алышуны башлап җибәрү, укучыларның аның уңаеннан үз фикерләрен әйтү, аңа карата үз карашларын булдыру-аларның эшен оештыру; | **6 сәг** |
| **Сан** | Сан турында төшенчә. Микъдар, тәртип саннары. Тест. Искәртмәле диктант. | -укучыларга җаваплы, гражданлык тәртипләренең, кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек күрсәтүләренең, уку өчен тиешле текстлар, мәсьәләләр, проблемалы ситуацияләр аша уку предметын карап тотуның тәрбия мөмкинлекләреннән файдалану. | **6 сәг** |
| **Рәвеш** | Рәвеш турында гомуми төшенчә. Сөйләмдә актив кулланылышлы рәвешләр һәм аларның дөрес язылышы. Рәвешләрнең мәгънәләре һәм җөмләдә кулланылышы. | -укучыларны дәрестә гомуми кабул ителгән тәртип нормаларын, өлкәннәр (педагогик хезмәткәрләр)белән аралашу | **5 сәг** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Изложение язу “Ябалак. Тавык. Аучы.” | кагыйдәләрен үтәргә өндәү;<br>-укучыларның тикшеренү эшчәнлегенә башлангыч бирү һәм ярдәм итү. | |
| **Кисәкчә** | Кисәкчәләрнең сөйләмдәге роле – мәгънә, хис төсмерләрен, раслау, инкяр итүне белдерүләре.аларны аралашу ситуациясенә һәм сөйләм максатына туры китереп урынлы, төгәл куллану. | -дәресләрдә социаль әһәмияткә ия булган мәгълүмат белән эшләү – аның турында фикер алышуны башлап җибәрү, укучыларның аның уңаеннан үз фикерләрен әйтү, аңа карата үз карашларын булдыру-аларның эшен оештыру; | **2 сәг** |
| **Бәйлекләр** | Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм алмашлыкларның бәйлекләр белән килүенә күзәтүләр. Баш, юнәлеш, чыгыш килешен таләп итә торган бәйлекләр, аларны сөйләмдә дөрес куллану.<br>Грамматик биремле контроль диктант.”Ана йөрәге” | -укучыларга җаваплы, гражданлык тәртипләренең, кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек күрсәтүләренең, уку өчен тиешле текстлар, мәсьәләләр, проблемалы ситуацияләр аша уку предметын карап тотуның тәрбия мөмкинлекләреннән файдалану. | **4 сәг** |
| **Сүзтезмә.** | Сүзтезмә. Сүзтезмәдә сүзләр бәйләнеше. | -дәрестә укучылар белән эшләүнеңинтерактив рәвешләрен куллану:укучыларның танып-белү мотивациясен стимуллаштыручы интеллектуаль уеннар; дидактик театр куллану, аларда дәрестә | **2 сәг** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | алган белемнәре ота белү; | |
| **Җөмлә** | **Җөмлә - 10сәг.** Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Аергыч. Җөмләнең тиңдәш кисәкләре.Эндәш сүзләр. Гади җөмлә һәм кушма җөмлә.<br><br>Изложение.”Кечкенә умартачы”. Тест. | -дәрескә укучыларның белем алуга мотивациясен, сыйныфта уңай дустанә мөнәсәбәтләр урнаштырырга ярдәм итүче уен процедураларын кертү дәрес вакытында дустанә атмосфера булдырырга ярдәм итә.;<br><br>- укучыларга җаваплы, гражданлык тәртипләренең, кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек күрсәтүләренең, уку өчен тиешле текстлар, мәсьәләләр, проблемалы ситуацияләр аша уку предметын карап тотуның тәрбия мөмкинлекләреннән файдалану.<br><br>-дәрестә укучылар белән эшләүнең интерактив рәвешләрен куллану: укучыларның танып-белү мотивациясен стимуллаштыручы интеллектуаль уеннар; дидактик театр куллану, аларда дәрестә алган белемнәре ота белү. | **10сәг** |
| **Сөйләм һәм текст** | **Сөйләм һәм текст –8 сәг.** Текст, аның темасы, төп фикере, бүлек башы, текстның кисәкләре, алар | -укучыларның тикшеренү эшчәнлегенә башлангыч бирү һәм | **8 сәг** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | арасындагы бәйләнеш, укучыларның текст планы турындагы белемнәрен гомумиләштерү. Текстларның төрләре. Хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү характерындагы текстларның төзелеше. Текстларның эчтәлеген тулысынча һәм кыскартып сөйләү. Телдән хикәяләр төзү. Сөйләм этикасы.<br><br>Сочинение “Безнең авылның табигате.” | ярдәм итү,бу исә укучыларга теоретик проблеманы мөстәкыйль хәл итү, үз идеяләрен формалаштыру һәм рәсмиләштерү күнекмәләрен, башка тикшеренүчеләр эшендә рәсмиләштерелгән башка идеяләргә карата ихтирамлы мөнәсәбәт күнекмәләрен, аудитория алдында халык алдында чыгыш ясау, аргументлау һәм үз карашларын яклау күнекмәләрен алу мөмкинлеге бирәчәк. | |
| **Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау** | Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау .Контроль диктант. Тест. | -дәресләрдә социаль әһәмияткә ия булган мәгълүмат белән эшләү – аның турында фикер алышуны башлап җибәрү, укучыларның аның уңаеннан үз фикерләрен әйтү, аңа карата үз карашларын булдыру-аларның эшен оештыру;<br>-укучыларның тикшеренү эшчәнлегенә башлангыч бирү һәм ярдәм итү | **4 сәг** |

**Календарь - тематик планлаштыру**

| № п/п | Бүлек исеме Дәрес темасы | Үткәрү вакыты | | Эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|---|
| | | план | факт | |
| 1. | **1-3 нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау-8сәг.** щ | 2.09 | | Авазларга характеристика бирү , хикәяләү тибындагы текст төзи белү |
| 2 | Сузык ,тартык  авазлар. Иҗек – әйтелешнең иң кечкенә берәмлеге. Дифтонг. Иҗек калыплары. Сүзләрне юлдан-юлга күчерү тәртибе. | 4.09 | | Сигармонизм законына буйсынган һәм буйсынмаган сүзләрне аеру һәм дөрес итеп язу.Хикәяләү тибындагы текст төзи белү |
| 3 | Җәйге истәлекләр буенча инша язу. | 5.09 | | Бәйләнешле сөйләм төзү.Хикәяләү тибындагы текст төзи белү<br>Сүзләрне дөрес итеп иҗекләргә бүлү, тамырда авазлар чиратлашуын белү<br>Сүзләрне юлдан-юлга күчерү кагыйдәләрен белү |
| 4 | Сүзләргә аваз-хәреф анализы ясау тәртибе. | 9.09 | | Сүзгә аваз-хәреф анализы ясау |
| 5 | Орфографик дөрес язу кагыйдәләре | 11.09 | | Орфографик дөрес язу кагыйдәләрен искә төшерү. Сүздә орфограммаларны табу, язуда дөрес куллану. |
| 6 | Сүз төркемнәре | 12.09 | | Сүзгә морфологик анализ ясау. |
| 7. | Җөмлә кисәкләре. | 16.09 | | Гади җөмләгә синтаксик анализ ясау. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8. | Кереш диктант | 18.09 | | Өйрәнгән орфограммалар кергән текстны ишетеп язу |
| 9 | **Сүз.Телнең сүзлек байлыгы-8 сәг.** Хаталар өстендә эш. Сүзнең лексик мәгънәсе. | 19.09 | | Аңлатмалы сүзлек ярдәмендә сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау. |
| 10 | Алынма сүзләр | 23.09 | | Гарәп, фарсы, рус телләреннән алынган сүзләр белән танышу. “Телнең лексик составы” төшенчәсен, сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, сүзлекләрнең төрен , алар белән эшләү тәртибен карау |
| 11 | Бер һәм күп мәгънәле сүзләр. | 25.09 | | Күп мәгънәле сүзләрне сөйләмдә дөрес куллану |
| 12 | Тотрыклы сүзтезмәләр | 26.09 | | Фразеологик әйтелмәләрне сөйләмдә куллану |
| 13 | Омонимнар | 30.09 | | Омонимнарны  сөйләмдә куллана белү |
| 14 | Синонимнар, антонимнар | 2.10 | | Охшаш, капма-каршы мәгънәле сүзләр кулланып бәйләнешле сөйләм төзү. |
| 15 | Изложение язу  “Усак” | 3.10 | | Бирелгән план буенча текстның кыскача эчтәлеген яза белү |
| 16 | Хаталар өстендә эш.Тест. | 7.10 | | Белем һәм күнекмәләрне ныгыту |
| 17. | **Сүз төзелеше-11сәг.** Сүз төзелеше. Тамыр һәм кушымча. Кушымча төрләре. | 9.10 | | Тамыр һәм кушымчаны аеру. Кушымчаларның төрен билгеләү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 18 | Сүз ясагыч кушымчалар | 10.10 | | Тамыр һәм кушымчаны аеру. Кушымчаларның төрен билгеләү.Сүзнең нигезен билгели белү |
| 19 | Сүз ясагыч кушымчалар | 14.10 | | |
| 20 | Картина буенча хикәя язу | 16.10 | | Белемнәрн |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | е практикада куллану . Бәйләнешле текст төзү. |
| 21 | Төрләндергеч кушымчалар | 17.10 | | Тамыр һәм кушымчаны аеру. Кушымчаларның төрен билгеләү, төрләндергеч һәм ясагыч кушымчаларны аера белү |
| 22 | Кушма сүзләр | 21.10 | | Кушма сүзләрнең ясалышын, дөрес язылышын белү |
| 23 | Кушма сүзләр | 23.10 | | |
| 24 | Парлы сүзләр.  Сүзлек диктанты | 24.10 | | Сызыкча аша язылучы ике тамырдан торган сүзләр белән танышу. Парлы сүзләрнең ясалышын, дөрес язылышын белү. |
| 25 | Тезмә сүзләр | 7.11 | | Тезмә сүзләрнең сүзтезмәдән аермасы карау |
| 26 | Контроль диктант “Дуслык сере” | 11.11 | | Өйрәнелгән орфограммалар кергән текстны хатасыз итеп яза белү |
| 27 | Хаталар өстендә эш | 13.11 | | Хата җибәрелгән орфограммаларны искә төшерү, шул орфограммага мисаллар табу |
| 28 | **Сүз төркемнәре. Исем-8 сәг.**<br>Исем турында үткәннәрне искә төшерү | 14.11 | | Кагыйдәләргә нигезләнеп сүзләрнең дөрес язылышын аңлату. Исемне таный, аера белү. |
| 29 | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. | 18.11 | | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре белән танышу , ялгызлык исемнәрен дөрес яза белү |
| 30 | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. | 20.11 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 31 | Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. | 21.11 | | Исемнәрнең берлектә һәм күплек тә килеш белән төрләнеше белән танышу |
| 32 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | 25.11 | | Өйрәнелгән орфограммалар кергән текстны хатасыз итеп күчереп язу, исемне килешләр белән төрләндерү |
| 33 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | 27.11 | | |
| 34 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Тест. | 28.11 | | |
| 35 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Изложение. "Хәйдәр коткарды" | 2.12 | | Текстның планын төзү, текстка карата сораулар бирү.Укылган текстның эчтәлеген язу |
| 36. | **Фигыль-13 сәг.**<br><br>Фигыль турында үткәннәрне искә төшерү. | 4.12 | | Фигыльнең төп билгеләрен белү, җөмләдә фигыльләрне таба белү |
| 37 | Хәзерге заман хикәя фигыль. | 5.12 | | Сөйләү моменты белән туры килүче, даими эш-хәлләр белән танышу. Кушымчаларның 4 варианты: -а/ -ә, -ый/ - и. Хәзерге заман хикәя фигыльне таный белү, зат-сан белән төрләндерә белү |
| 38 | Хәзерге заман хикәя фигыль. | 9.12 | | |
| 39 | Үткән заман хикәя фигыль | 11.12 | | Билгеле үткән заман -ды/-де, -ты/-те кушымчалары, билгесез үткән заман -ган/-гән, -кан/-кән кушымчалары, зат-сан белән төрләнүе. Үткән заман хикәя фигыльне таный белү, зат-сан белән төрләндерә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 40 | Үткән заман хикәя фигыль | 12.12 | | белү |
| 41 | Киләчәк заман хикәя фигыль. | 16.12 | | Билгеле киләчәк заман -ачак /-әчәк, -ячак /-ячәк кушымчалары,билгесез киләчәк заман -ыр /-ер, -ар /-әр,-р кушымчалары, зат-сан белән төрләнүе |
| 42 | Киләчәк заман хикәя фигыль. | 18.12 | | |
| 43 | Іяртыеллык өчен контроль диктант | 19.12 | | Өйрәнелгән кагыйдәләр кергән текстны ишетеп язу, биремнәрне<br><br>үтәү |
| 44 | Хаталар өстендә эш.<br><br>Боерык фигыль | 23.12 | | Боерык фигыль белән танышу. Боерык фигыльләрне текстта аеру |
| 45 | Боерык фигыльнең төрләнеше | 25.12 | | Боерык фигыльнең берлек һәм күплек санда зат-сан белән төрләнүе. |
| 46 | Боерык фигыльнең төрләнеше | 26.12 | | |
| 47. | Антоним һәм синоним фигыльләр | 9.01 | | Фигыльләргә антонимнар, синонимнар табу. Антоним һәм синоним фигыльләрне бәйләнешле сөйләм төзегәндә куллану. |
| 48. | Үткәннәрне ныгыту .Тест. | 13.01 | | Хата җибәрелгән орфограммаларны искә төшерү, шул орфограммага мисаллар табу. Фигыльнең өйрәнелгән билгеләрен белү, сүз төркеме булу ягыннан тикшерү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 49. | **Сыйфат-7 сәг.**<br><br>Сыйфат турында үткәннәрне кабатлау. | 15.01 | | Сыйфатларны тексттан табу.  Сыйфатның соравын, нәрсә белдерүен белергә, җөмләдә таба белергә тиеш |
| 50 | Сыйфат дәрәҗәләре. | 16.01 | | Төп,артыклык, чагыштыру, кимлек  дәрәҗәсендәге сыйфатларны карау.  Төрле дәрәҗәдәге сыйфатларны аеру |
| 51 | Сыйфат дәрәҗәләре. | 20.01 | | |
| 52 | Сыйфатларныңҗөмләдәге функциясе . Аергыч, хәбәр. | 22.01 | | Җөмләгә синтаксик анализ.  Сыйфатның лексик-семантик үзенчәлекләре,  аның җөмләдәге роле белән танышу. |
| 53 | Синоним һәм антоним сыйфатлар. | 23.01 | | Синоним һәм антоним сыйфатлар белән мәгънәле, тәэсирле сөйләм оештыру күнегүләре. Синоним һәм антоним сыйфатлар кулланып бәйләнешле сөйләм төзү |
| 54 | Сочинение “Керпе”. | 27.01 | | Бәйләнешле сөйләм төзү |
| 55 | “Сыйфат” темасын кабатлау. Тест. | 29.01 | | Сыйфат темасын кабатлау һәм белемнәрен тикшерү |
| 56 | **Алмашлык -6 сәг.**<br><br>Зат алмашлыклары. | 30.01 | | Зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнеше һәм дөрес язылышы. Зат алмашлыкларын тану, килешләр белән төрләндерү, җөмләдә дөрес куллану |
| 57 | Зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнеше. | 3.02 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 58 | Зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнеше. | 5.02 | | |
| 59 | Сорау алмашлыклары. | 6.02 | | сорау алмашлыклары. Аларның килеш белән төрләнеше |
| 60 | Сорау алмашлыклары. | 10.02 | | |
| 61 | Аңлатмалы диктант “Аны һәркем ярата”. | 12.02 | | Өйрәнелгән кагыйдәләр кергән текстны ишетеп язу. Тест биремнәрен эшләү. Өйрәнелгән орфографик һәм пунктацион кагыйдәләрне кулланып, хатасыз язу |
| 62 | **Сан-6 сәг.**<br>Хаталар өстендә эш. Сан турында төшенчә. | 13.02 | | Сан турында беренчел күзаллау. Сан һәм саналмышның үзара ярашуы. Саннарны саналмышлары белән бергә  таба белергә, аларны үзара дөрес яраштыра |
| 63 | Микъдар саннары. | 17.02 | | Микъдар саннары турында төшенчә бирү,саннарныңлексик-семантик үзенчәлекләре белән танышу. |
| 64 | Микъдар саннары. | 19.02 | | |
| 65 | Тәртип саннары . | 20.02 | | Тәртип саннары белән танышу |
| 66 | Тәртип саннары . Тест | 24.02 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 67 | Искәртмәле диктант. | 26.02 | | Өйрәнелгән кагыйдәләр кергән текстны ишетеп язу. Тест биремнәрен эшләү. |
| 68 | **Рәвеш-5 сәг.**<br><br>Хаталар өстендә эш. Рәвеш турында гомуми төшенчә. | 27.02 | | Рәвешнең мәгънәләре һәм җөмләдә кулланылышы белән танышу. Җөмләдә рәвешне тану. |
| 69 | Телдә еш кулланыла торган рәвешләр. | 2.03 | | Рәвешләрнең дөрес язылышы. Телдә еш кулланыла торган рәвешләрне дөрес язу |
| 70 | Рәвешләрнең дөрес язылышы. | 4.03 | | |
| 71 | Изложение язу “Ябалак. Тавык. Аучы.” | 5.03 | | Бирелгән тема буенча укучыларның  алган белемнәренә нигезләнеп, изложение язу, өйрәнелгән сүзләр куллану, эзлеклелек, дөрес язылыш |
| 72 | Рәвешләрне куллануга карата күнегүләр эшләү. | 9.03 | | Рәвешнең мәгънәләре һәм җөмләдә кулланылышы. |
| 73 | **Кисәкчә-2 сәг.**<br><br>Кисәкчә турында төшенчә. | 11.03 | | Кисәкчә. Кисәкчәләрнең сөйләмдәге роле.<br><br>Кисәкчәләрнең мәгънә, хис төсмерләрен, раслау, инкяр итүне белдерүләре.<br><br>Кисәкчәләрне сөйләмдә урынлы, дөрес куллану. |
| 74 | Кисәкчәләрнең дөрес язылышы. | 12.03 | | |
| 75 | **Бәйлекләр-4 сәг.**<br><br>Бәйлекләр. | 16.03 | | Бәйлекләр һәм аларны сөйләмдә дөрес куллану<br><br>Баш, юнәлеш, чыгыш килешләрен таләп итүче бәйлекләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 76 | Бәйлекләр. | 18.03 | | |
| 77. | Грамматик биремле контроль диктант.”Ана йөрәге” | 19.03 | | Өйрәнелгән орфограммаларны кулланып диктант язу, сүз төркемнәрен табу |
| 78. | Хаталар өстендә эш. Үткәннәрне ныгыту. | 1.04 | | Кабатлауга күнегүләр эшләү. Кагыйдәләргә нигезләнеп, сүзләрнең дөрес язылышын аңлату |
| 79 | **Җөмлә.Сүзтезмә-12 сәг.**<br>Җөмлә. | 2.04 | | Сүзтезмә, сүзтезмәдә сүзләр бәйләнешен ачыклау |
| 80 | Сүзтезмә. | 6.04 | | |
| 81 | Җөмләнең баш кисәкләре. | 8.04 | | Җөмләнең баш кисәкләре: ия белән хәбәрне табу. |
| 82 | Ия һәм хәбәр | 9.04 | | |
| 83 | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр | 13.04 | | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр арасындагы аерма, күнегүләр эшләү. Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне тексттан табу. |
| 84 | Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч. | 15.04 | | Җөмләнең иярчен кисәге аергыч турында төшенчә, җөмләгә синтаксик анализ ясау. Баш кисәкләрдән чыгып сорау кую юлы белән җөмләнең иярчен кисәкләрен табу |
| 85 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре | 16.04 | | Җөмлә кисәкләренең тиңдәшләнеп килүе.Тиңдәш баш һәм иярчен кисәкләрне табуга күнегүләр эшләү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 86 | Эндәш сүзләр | 20.04 | | Эндәш сүзләр турында төшенчә . Җөмләдә эндәш сүзләне табу, алар янында тыныш билгеләрен кую. Эндәш сүзләрне сөйләмдә куллану. |
| 87 | Гади һәм кушма җөмлә. | 22.04 | | Җыйнак һәм җәенке гади җөмлә. Ике гади җөмләдән торган тезмә кушма җөмлә. Гади һәм кушма җөмләләрне тану һәм аеру |
| 88 | Гади һәм кушма җөмлә. | 23.04 | | |
| 89 | Изложение.”Кечкенә умартачы” | 27.04 | | Бирелгән тема буенча укучыларның алган белемнәренә нигезләнеп, ижложение язу, өйрәнелгән сүзләр куллану, эзлеклелек, дөрес язылыш |
| 90 | Хаталар өстендә эш.Үткәннәне кабатлау. Тест. | 29.04 | | Кагыйдәләргә нигезләнеп, сүзләрнең дөрес язылышын аңлату |
| 91 | **Текст. Бәйләнешле сөйләм-8 сәг.**<br>Текст. Тема. | 30.04 | | Текст, җөмләләр арасындагы бәйләнеш,темасы һәм өлешләре. Текстның кисәкләре, алар арасындагы бәйләнеш. Текстның темасы һәм төп фикере. |
| 92 | Текст өлешләре | 4.05 | | |
| 93 | Сөйләм этикасы | 6.05 | | Сөйләм күнекмәсен үстерү өстендә эш. Төрле ситуацияләрдә тылсымлы сүзләрне дөрес куллану, кеше хәленә керү |
| 94 | Сөйләм этикасы | 7.05 | | |
| 95 | Текст төрләре. Хикәяләү. | 11.05 | | Бирелгән темага төрле типтагы текстлар төзү. Хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү характерындагы текстларны аеру сөйләмдә куллану |
| 96 | Текст төрләре. Тасвирлау. | 13.05 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 97 | Текст төрләре. Фикерләү. | 14.05 | | |
| 98 | Сочинение “Безнең авылның табигате” | 18.05 | | Тасвирлау тексты төзү. Текстның планын төзү һәм план буенча эчтәлеген язу |
| 99 | **Үткәннәрне кабатлау-2 сәг.**<br>Үткәннәрне кабатлау. | 20.05 | | Кагыйдәләргә нигезләнеп, сүзләрнең дөрес язылышын аңлату |
| 100 | Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау-гомумиләштерү. | 21.05 | | |
| 101 | Арадаш аттестация эше | 25.05 | | Өйрәнелгән орфографик һәм пунктацион кагыйдәләрне кулланып, хатасыз язу |
| 102 | Хаталар өстендә эш. Тест. | 27.05 | | Өйрәнелгән орфографик һәм пунктацион кагыйдәләрне кулланып, хатасыз яза белергә тиеш |

Основная литература:

1.Татарский язык: учебник для 4 класса начальной общеобразовательной школы с татарским языком обучения. В двух частях. Часть 1 /И. Х. Мияссарова, К. Ф. Файзрахманова Казань. Издательство «Магариф-Вакыт», 2014.

2. Татарский язык: учебник для 4 класса начальной общеобразовательной школы с татарским языком обучения. В двух частях. Часть 2 /И. Х. Мияссарова, К. Ф. Файзрахманова Казань. Издательство «Магариф-Вакыт», 2014.
Дополнительная литература:
1.С. Г. Вагизов,Р. Х. Ягфарова. Программа обучения татарскому языку для 1-4 классов начальной общеобразовательной школы на татарском языке. Казан. Книжный фонд Татарстана. 2010.
2.Р. А. Абдуллина, М. Х. Ханнанова. Тесты по татарскому языку.Издательство” Гилем", 2012 3.М.
З. Ахиярова, И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина. Обучение татарскому языку творческим сочинениям и изложениям. Издательство” Магариф", 2009.
4.Татарские народные загадки и пословицы.
5.Русско-татарский толковый словарь. Татарское книжное издательство
6. Сборник диктантов

**Укыту - методик кулланма исемлеге**

1. Татар теле: татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе 4 нче сыйныфы өчен дәреслек. 1 нче кисәк / И.Х.Мияссарова, К.Ф.Фәйзрахманова – Казан: ”Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2014 нче ел
2. Татар теле: татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе 4 нче сыйныфы өчен дәреслек. 2 нче кисәк / И.Х.Мияссарова, К.Ф.Фәйзрахманова – Казан ”Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2014 нче ел
3. Татар теле. Методик ярдәмлек. 4 сыйныф “Мәгариф-вакыт” нәшрияты 2014 ел Авторлар: И.Х.Мияссарова, К.Ф.Фәйзрахманова
Өстәмә әдәбият:
1.С.Г.Вагыйзов,Р.Х.Ягъфәрова. Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1-4 нче сыйныфлары өчен татар телен укыту программасы. Казан. Татарстан китап нәрияты. 2010.
2.Р.Ә.Абдуллина, М.Х.Ханнанова. Татар теленнән тестлар.”Гыйлем” нәшрияты,2012
3. М.Җ.Ахиярова, И.Х.Мияссарова, Ф.Ш.Гарифуллина. Татар теленнән иҗади сочинениеләр һәм изложениеләр язарга өйрәтү. “Мәгариф” нәшрияты,2009.
4.Татар халык табышмаклары һәм мәкальләре.
5.Русча-татарча аңлатмалы сүзлекчә.ФДББС.Татарстан китап нәшрияты, 1014.
6. Диктантлар җыентыгы

**Информацион-компьютер ярдәмлек:**

http://www.school.edu.ru/ http://school-collection.edu.ru/
http://nsc.1september.ru/urok/ http://www.openclass.ru/
www.edu.tatar.ru

Кушымта

Татар теленнән 4 нче сыйныфлар өчен якынча контроль диктант текстлары

Кереш диктант

Көз якынлаша.

Август ахырында җәйге шат урман моңсулык белән очраша. Куәтле имәннәр, аларның кече туганы өрәңгеләр, калын киемле юкәләр әле ямь - яшелләр, шат һәм көр күңеллеләр. Ә менә бөдрә каеннар, нечкәбил усаклар, зифа миләшләр көз якынлашуын әллә кайдан сизеп алганнар. Каенның нәфис яфраклары арасында алтынсу төскә кергәннәре шактый. Усак күп кенә яфракларын көрәнсу һәм лимон сарысына бизәп өлгергән. Ут тәлгәшле миләшнең телем- телем яфраклары да җимешләре кебек кызарганнар. (64 сүз.)

Изложение.

Усак.

Усакның яфраклары вак. Алар ботакларга нечкә озын саплар белән беркетелгән була. Шуңа күрә бертуктаусыз хәрәкәтләнеп, бер-берсенә бәрелеп шаулыйлар. Хәтта җилсез көнне дә усак урманында яфраклар өзлексез кыштырдап утыралар.

Кайберәүләр усакны агачка да санамыйлар. Имеш, усак- черек агач. Алай уйлау дөрес түгел. Усактан салынган өй йөз еллап чыдый. Усак агачы гөмбәгә һәм төрле кортларга бирешми. Коры усак агачы җиңел, нык. Өрлек, түшәм һәм идән өчен яхшы. Кое бурасы ясау өчен әйбәт. Усак савыт-сабалар, шырпы эшләүдә, уенчыклар һәм химик әйберләр әзерләүдә кулланыла.

Элек кешеләр, өйләрен яктырту өчен, усак чырасыннан файдаланганнар. Ул якты ялкын чыгарып яна. (93 сүз.)

I чирек нәтиҗәләре буенча контроль диктант.

Төлке.

Төлке куянның иң куркыныч дошманы дип санала. Ул чынлап та куяннарны, бигрәк тә аларның балаларын аулый. Ләкин төлкенең төп азыгы – тычканнар. Башын иеп тыңлагандай, еш –еш туктап, ашыкмыйча гына кар өстеннән йөри икән, димәк, төлке тычканнар аулый. Ул шундый сизгер, кар астындагы тычканның тавышын йөз метрдан ишетә. Сикереп төшә дә, ак тузаннар туздырып, карны казырга тотына, тычканны эләктереп тә ала.

Төлкеләр ачыклыкта кар өстенә ятып ял итәләр. Ачык басуда кар өстендә яту аларга куркыныч түгел, чөнки тирә – як күренеп тора. (78 сүз.)

Изложение.

Хәйдәр коткарды.

Хәйдәрнең мине үлемнән коткаруы тимераякта йөргәндә булды.

Кар ятмаган әле. Мәктәптән кайтканда карасак, боз туңган. Яр читендә- пыяла шикелле.

Төштән соң киттек тегермән буасына. Ә буа киң. Уртасында зур бер утравы да бар. Уртага кергән саен, бозы ныграк кебек. Шундый тигез, шома! Мин иркенгә- утрау ягына элдерәм генә!

Алга карасам, ни күзем белән күрим, бәләкәйрәк күл кадәр су! Читкә борылып та өлгермәдем- бар да чум!

Боз өстендә Хәйдәр генә. Миңа таба килде дә аяк-кулларын җәеп, бозга капланып ятты. Шуышып килде. Кулдан тотып алды да ашыкмый гына тартты.

Кыю дустым Хәйдәр булмаса, чыга алмаган булыр идем. (95 сүз.)

II чирек нәтиҗәләре буенча контроль диктант.

Дуслык сере.

Көз якынлашуга тиз генә исе китми торган бер агач бар. Ул – чикләвек агачы. Нигә ул кара көзгә хәтле яфракларын коймый? Тәмле чикләвекләрен кеше күзеннән яшереп саклап калыр өчен икән. Дусты тиен өчен саклый ул чикләвекләрен. Тиен исә аларны бик оста табып ала, шулар белән туенып, кыш чыга. Күпмедер чикләвекне тиен агач куышлыгында, тамыр төпләрендә онытып калдыра. Яшерелгән ул чикләвекләрдән үсентнеләр калкып чыга.(64 сүз)

Аңлатмалы диктант.

Аны һәркем ярата.

Минем әнине бар кеше дә ярата. Ә мин аны бар кешедән дә артыграк яратам. Яратырлык шул минем әни!
Ничек итеп яратмыйсың инде аны. Беркөнне менә нинди хәл булды.

Безнең әнине күршедәге бер апа килеп чакырды. Бик ялынгач, әни мине дә алып барырга булды. Без әни белән икәүләп киттек. Йөгерә – йөгерә бардык.Әни дә йөгерде, мин дә. Шундый ашыккан вакытта комачавы да чыгып тора тагын. Капкаларын ачуга, бер зур эт өстебезгә ташланды. Мин алдарак идем. Ул туп – туры минем өскә килә. Әни эт белән минем арага кермәсенме?

Әни мине эттән саклап калды. Сез тагын аны шуның өчен ярата дип уйламагыз. Мин әниемне бигрәк тә кешеләрне авырудан котылдыруы өчен яратам.

Искәртмәле диктант.

Чәүкә.

Җыелышта сүз Чәүкәгә бирелде. Ул сөйли башлады:

-Без бик ишле. Без очканда йөзәрләп, бишәр йөзләп, хәтта меңәрләп очабыз. Без кешеләргә, елгаларга якын урында торырга яратабыз. Безнең ояларыбыз бер – берсеннән беркайчан да ерак булмый. Без бер төп өянке башында утызлап, иллеләп оя ясыйбыз. Безнең бергәләп яшәү корткычларга каршы көрәшү өчен уңай.

Изложение.

Ябалак, тавык, аучы.

Ябалак бик түбән кунаклавын белмәде. Аның күзләре яхшылап күрмәде. Инде яктырган иде. Матур куак сайлап оча торган кошлар да йокыдан уянганнар иде.

Ябалак үзенең тырнаклары арасында тыпырчынган тавыктан көлде:
-Ябалаклар яктыргач йоклыйлар. Көндез күрүнең нигә кирәге бар? Төнлә дисәң, менә әйтсәң дә ярый. Кемнең күзе яхшы күрә, шул сезнең кебек юләр тавыкларны тотып ала. Үзенә тәмле азык таба. Мин сине рәхәтләнеп ашармын...
Оста аучы куакларга посып кына килде. Мылтык тавышы ишетелде. Яфраклар селкенештеләр. Ябалак һәм аның тырнакларындагы тавык җиргә егылып төштеләр.

- Бер атуда ике кошны бәреп төшердем, -дип шатланды аучы.
- Зирәк кешенең күзләре көндез дә, төнлә дә яхшы күрә шул. (100 сүз.)

III чирек нәтиҗәләре буенча контроль диктант.

Ана йөрәге.

Беркөнне Сәлимә әби белән Зөфәр мәктәп бакчасына керделәр. Аллы – гөлле чәчәкләр арасында һәйкәл куелган. Монда Сәлимә әбинең геройларча һәлак булган улы Газизнең дә исеме язылган. Сәлимә әбинең йөрәге дөп-дөп типте. Ул кинәт туктап калды һәм

күкрәгән тотты. Аның аяк буыннары хәлсезләнде. Аларны зурлап каршы алган мәктәп директоры әбинең хәлен бик тиз аңлады. Ул аңа утырырга урын күрсәтте. Шул арада Зөфәр дә бакча мәйданындагы мәгърур һәйкәлне күреп алды һәм шунда ашыкты. Сәлимә әбигә дә бераз хәл керде. Ул акрын гына башын  югары күтәрде һәм улы Газиз янына атлады. (86 сүз.)

Изложение.

Кечкенә умартачы.

Чәй эчеп бетермәгән идек. Хәкимнәр килеп тә җитте. Тубал гына алып килмәгән икән ул. Калайдан ясалган төтен савыты, каен кайрысыннан ясалган кашык, җәтмәдән ясалган битлек, тагын башка нәрсәләр.

Хәким, битлекне кигәч, кулга кашыкны ипләп тоткач, тәмам кечкенә умартачы булды. Атасы янында йөри-йөри шомарган, умартачы булган да беткән икән. Ул төтен савытын кабызды да тубалны җиргә куйды. Аның эченә кортлар сарган ботакларны кертеп, аз гына төтен җибәрде. Ун минут эчендә агач ботагындагы кортлар тубал эченә кереп беттеләр.

- Беләсезме, ник тиз җыелдылар алар?- диде Хәким.
- Без бер сүз дәшә алмадык. Соравына үзе җавап бирде:
- Тубалга лимон мае сөрткән идем. Умарта кортлары аны бик яраталар. (102 сүз.)

IV чирек нәтиҗәләре буенча контроль диктант.

Җырчы кош.

Көннәр буе ары-бире чапса да, Чи-чи болында үз ишләрен таба алмады. Тагын куаклыкка барып чыкты. Куаклар артында таныш  елга шавы ишетелә иде. Тычкан баласына кире борылып йөгерергә туры килде. Төне буе йөгерде дә яктыра башлагач кына ниндидер бер куак төбенә ятып ял итәргә булды.

Кемдер җырлаган тавышка уянып башын күтәреп караса, исе китте. Алсу  түшле, соры башлы, кызгылт каурыйлы бер кош икән.

Җыры бик ошады тычкан баласына. Якыннанрак тыңламакчы булып, өскә үрмәләде.
(72 сүз.)

Арадаш аттестация өчен контроль диктант.

Аңлатма язуы

Арадаш аттестация 4 сыйныф укучыларының татар теленнән ел буена алган белем һәм күнекмәләрен тикшерү һәм бәяләү максатыннан түбәндәге бүлекләр буенча үткәрелә:

1. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре.
2. Парлы сүзләр.
3. о/ө хәрефләренең язылышы.
4. Җөмләнең баш  кисәкләре.
5. Кисәкчәләр.

Арадаш  аттестация эше түбәндәге чыганакларга таянып эшләнде:

- Мияссарова И.Х., Фәйзрахманова К.Ф. Татар теле: 4 нче сыйныф: дәреслек: 1—2 кисәк. Казан: «Мәгариф- Вакыт» нәшрияты, 2014.
- Мияссарова И.Х., Фәйзрахманова К.Ф. Татар теле: 4 нче сыйныф: укытучы ечен методик кулланма. Казан: «Мәгариф— Вакыт» нәшрияты, 2014.

Арадаш аттестацияне үткәрү төре: грамматик биремле диктант.
Үткәрү өчен 45 минут вакыт карала.
Бәяләү критерийлары:

Хаталары булмаган, төзәтүләрсез эшкә «5»ле билгесе куела.

3 хатага (ике орфографик һәм бер пунктуацион хата; бер орфографик, бер грамматик, бер пунктуацион хата; бер орфографик һәм ике пунктуацион хата һ.б.) «4»ле билгесе куела.

5 хатага (ике орфографик һәм өч пунктуацион хата; ике орфографик, бер грамматик һәм ике пунктуацион хата булса һ.б.) «3»ле билгесе куела.

5 хатадан күбрәк- «2»ле билгесе куела (алты орфографик, өч грамматик һәм өч пунктуацион хата; биш орфографик, ике грамматик һәм биш пунктуацион хата булса һ.б.).

Грамматик биремне бәяләү критерийлары:
«5» – барлык биремнәр дә дөрес һәм аңлап эшләнгән эшкә куела;
«4» – укучы биремнәрне аңлап эшләгән, ләкин 1-2 төгәлсезлек җибәрелгән;
«3» – укучы биремнәрнең яртысын аңлап эшләгән, әмма 3-4 төгәлсезлек җибәргән;
«2» – укучы биремнәрне аңламаган, күп эшне үти алмаган.

Ямьле Агыйдел буйлары.

Ямьле лә Агыйдел буйлары!

Күк йөзе эреле-ваклы йолдызлар белән тулы. Йолдызларның шәүләләре Агыйдел төбенә алтын багана булып сузылган. Йолдызлар уртасында – тулган ай. Ай үзенең алтын нурларын җиңел генә тирбәлеп торган Агыйдел өстенә сибә. Мондый кичләрдә Агыйдел буйлап юлга чыксаң да күңелле. Син атлыйсың, ә ай синең белән бергә бара.

Менә айны вак кына юка болытлар томалап ала. Мондый чакта Агыйдел өстендәге ай нурлары югала, су өсте моңсулана.

Тирә-яктан нинди тынлык! Шундый тыныч – теләсәң, үз йөрәгеңнең типкәнен дә ишетә аласың.(79 сүз.)

Грамматик бирем:

1. Кисәкчәләрнең астына сыз:
   1 вариант- бишенче җөмләдә;
   2 вариант- алтынчы җөмләдә.
2. Җөмләнең баш кисәкләрен билгелә:
   1 вариант- өченче җөмләдә;
   2 вариант- бишенче җөмләдә.

Укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләрен язмача тикшерү һәм бәяләү

“5” - хаталар һәм төзәтүләр юк, эш пөхтә, ачык язылган. Язу каллиграфия таләпләренә туры килә (хәрефләрнең формалары дөрес, бертөрле биеклектә, хәрефләр арасында тигез ара). Каллиграфия нормаларыннан бер генә чигенеш яки бер төзәтү булырга мөмкин (төшеп калган хәрефне өстәү, төгәл язылмаган хәрефне төзәтү).
“4” - диктантта 2 орфографик, 1 пунктацион хата яисә 1 орфографик, 2 пунктацион хата. Эш пөхтә башкарылган, ләкин каллиграфия таләпләре үтәлмәгән. Шуңа өстәп, берәр “5” билгесендә күрсәтелгән төзәтүләр булырга мөмкин.
“3” - диктантта 3 тән 5 кә хәтле орфографик хата (3орфографик, 2 пунктацион яисә 5 орфографик һәм 1  пунктацион хата). Эш җиренә җиткереп башкарылмаган, каллиграфия нормаларыннан җитди тайпылышлар. Төрле характердагы төзәтүләр булырга мөмкин.
“2” - диктантта 6-7 орфографик хата. Эш тырышып башкарылмаган, каллиграфия нормалары үтәлмәгән.
Сүзлек диктантларын, конроль күчереп язуны бәяләү нормалары:
“5” – хатасыз эш
“4” -  1 хата, 1 төзәтү
“3” – 2 хата, 1 төзәтү
“2” – 3-4 хата яки 3 хата, 1-2 төзәтү

Диктант һәм күчереп язу өчен тәкъдим ителгән текстларның күләме

I  чирек - 65 сүз
II чирек - 70 сүз
III чирек - 75 сүз
IV чирек - 80 сүз